КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 июнь г.Казань № 460

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 гыйнвар, 29 нчы; 2016 ел, 2 сентябрь, 612 нче; 2017 ел, 21 март, 161 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1115 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1230 нчы; 2019 ел, 3 май, 376 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программага, V бүлекнең 1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«21) вентиляция каналларын һәм төтен юлларын ремонтлау.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин